РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур., 14 йорт,
Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

______________20_____ел. № __________

«2040 елга кадәр Азнакай шәһәрендә
җылылык белән тәэмин итү схемасы»
проекты буенча гавами тыңлауларны
билгеләү турында (2024 елга актуальләштерү)

Азнакайда яшәүчеләрнең җылылык белән тәэмин итү системасының нәтиҗәле һәм имин эшләве, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә хокукый җайга салуны исәпкә алып, аны үстерү мәсьәләләре буенча фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә:

1. «2040 елга кадәр Азнакай шәһәрендә җылылык белән тәэмин итү схемасы» проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә. (2024 елга актуальләштерү)

2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы итеп - Азнакай шәһәре Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы бүлеге (алга таба - шәһәр хуҗалыгы бүлеге);
- үткәрү вакыты - 2023 елның 15 ноябреннән 2023 елның 15 декабренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт;
- 2023 елның 15 декабренә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: – Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт, шәһәр хуҗалыгы бүлеге (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

3. Шәһәр хуҗалыгы бүлегенә:

Гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда «2024 елга кадәр Азнакай шәһәрендә җылылык белән тәэмин итү схемасы» проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.Ф.Миндубаева